ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БЕГИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Клубная д. 1, с. Бегишево, Заинский район, 423511

Клубная урамы, 1нче йорт, Бигеш авылы, Зәй районы, 423511

Телефон, факс 3-82-25. Электронный адрес:Beg.zai@tatar.ru,сайт:http://zainsk.tatarstan.ru/rus/ begishevskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 5** **07.04.2021 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына таянып,

## карар бирәм:

1. 2021 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында" 2020 елның 31 декабрендәге 03 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

2.1. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2021 елның 05 февралендәге 01 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **И.Р.Вәлиев.**

Зәй муниципаль районы
Бигешавыл җирлеге
башкарма комитетының
07. 04. 2021 ел
5 номерлы карарына
1 нче кушымта

2021 елның 01 февраленнән
Бигешавыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 443,73 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1044,51 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 936,74 |
| Барысы | 6424,98 |

Зәй муниципаль районы
Бигешавыл җирлеге
башкарма комитетының
07. 04. 2021 ел
5 номерлы карарына
2 нче кушымта

Бигешавыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 670,08 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1823,71 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1019,54 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2911,65 |
| Барысы | 6 424,98 |